КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 807

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр исәбеннән) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 490 нчы карары белән расланган Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр исәбеннән) субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

23 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерциягә карамаган оешманың Министрлык тарафыннан коммерциягә карамаган оешманың субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә коммерциягә карамаган оешманың субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

24 пунктның бишенче абзацында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләренә «мәгънәләре» сүзен өстәргә;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Коммерциягә карамаган оешма квартал саен Министрлыкка хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең үрнәк формасына кушымта итеп бирелә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

29 пунктта:

беренче абзацта «, максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Министрлык тарафыннан, шул исәптән әлеге Тәртип һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә гамәлгә ашырыла торган субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерү;

дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла торган тикшерүне.»;

30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

«31. Коммерциягә карамаган оешма әлеге Тәртипнең 29 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару срокларын бозганда, вәкаләтле орган, субсидия кире кайтарылу срогы чыккан көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының 2022 елда үтәчәк һәм уздыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 15 декабрь, 1074 нче карары белән расланган 2021 елда Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының 2022 елда үтәчәк һәм уздыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия булган чыгымнарны (чыгымнарны), финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булып торучы чыгымнар (чыгымнар);

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсе;

субсидия күчерү тәртибе;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, шулай ук өстәмә хисап кирәк булганда хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турында;

моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Кирәк булганда Министрлык субсидияләр алучылар белән килешүгә өстәмә килешү төзи, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формалар нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк рәвешләренә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча, квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр субсидияләр бирү (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта) нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән

тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.»;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

29 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

31 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 декабрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 15 ноябрь, 1085 нче карарына, 3 пунктта «29» саннарын «28» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

әлеге карар белән расланган Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү кысаларында чараларның җаваплы үтәүчеләре хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия булган чыгымнарны (чыгымнарны), финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булып торучы чыгымнар (чыгымнар);

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсе;

субсидия күчерү тәртибе;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, шулай ук өстәмә хисап кирәк булганда хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турында;

моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Кирәк булганда Министрлык субсидияләр алучылар белән килешүгә өстәмә килешү төзи, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формалар нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк рәвешләренә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча, квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр субсидияләр бирү (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта) нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.»;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

29 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

31 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1341 нче карары белән расланган Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләр финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы булган чыгымнарның (ака тотуларның) юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия күчерү тәртибе;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта - субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, шулай ук өстәмә хисап кирәк булганда хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары булган чыгымнарны гамәлгә ашыру

мөмкинлеген күздә тота торган шарт, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, аларны куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта - субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы турында;

моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Кирәк булганда Министрлык субсидияләр алучылар белән килешүгә өстәмә килешү төзи, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формалар нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк рәвешләренә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча, квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр субсидияләр бирү (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта) нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.»;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

30 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

32 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммер-циягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 14 март, 227 нче карары белән расланган 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммер-циягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;

субсидия бирү нәтиҗәсе зурлыгы;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисап бирү сроклары һәм формалары, шулай ук кирәк булганда өстәмә хисап;

субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Кирәк булганда Министрлык субсидияләр алучылар белән килешүгә өстәмә килешү төзи, шул исәптән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формалар нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Субсидия алучы квартал саен хисап кварталыннан соң килүче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең (шартнамәнең) үрнәк формасына китерелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешүе турында хисап тапшыра.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

25 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

6. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлне туктатырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр исәбеннән) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 490 нчы карары белән расланган Мәдәният өлкәсендә краудфандинг проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр исәбеннән) субсидияләр бирү тәртибенең 10 пунктның 8 пунктындагы өченче абзацы, 10 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацы һәм әлеге Тәртипкә кушымтаның унтугызынчы абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының 2022 елда үтәчәк һәм уздыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 15 декабрь, 1074 нче карары белән расланган 2021 елда Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының 2022 елда үтәчәк һәм уздыруга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктының өченче абзацы, 10 пунктының җиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 декабрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 15 ноябрь, 1085 нче карары белән

расланган Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү кысаларында чараларның җаваплы үтәүчеләре хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 9 пунктының өченче абзацы, 10 пунктының җиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1341 нче карары белән расланган Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктының өченче абзацы, 10 пунктының җиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммер-циягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 14 март, 227 нче карары белән расланган 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммер-циягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 9 пунктының өченче абзацы, 10 пунктының алтынчы абзацы.

7. Әлеге карар, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кертә торган әлеге карарның 1 пунктындагы унбишенче абзацыннан, 3 пунктындагы егерме алтынчы абзацыннан, 4 пунктындагы егерме бишенче абзацыннан, 5 пунктындагы егерме беренче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин